ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«30» 10 2023 г.

**КАРАР**

№ 256

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Инвестиция советы төзү турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районы территориясендә эшмәкәрлек эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итү, эшмәкәрлек структураларын районның социаль-икътисадый проблемаларын хәл итүгә җәлеп итү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдырганда һәм гамәлгә ашырганда эшмәкәрләрнең мәнфәгатьләрен исәпкә алу максатларында, Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1.Балтач муниципаль районының Инвестиция советын төзергә.

2.Түбәндәгеләрне расларга:

1)Балтач муниципаль районының Инвестиция советы турында нигезләмәне 1 нче кушымтага таянып.

2)Балтач муниципаль районының Инвестиция советы составын 2 нче кушымта нигезендә.

3.Балтач муниципаль район башлыгының «Балтач муниципаль районы Инвестиция Советы төзү турында» 2014 елның 18 июлендәге 135 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль
районы башлыгы

Р.Р.Нотфуллин

1 нче кушымта
Балтач муниципаль районы
башлыгының 2023 елның
256 номерлы
«30» 10 2023
карары белән расланган

# Балтач муниципаль районының Инвестиция советы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Инвестиция советы (алга таба - Инвестиция советы) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

2. Инвестиция советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, Балтач муниципаль районы Уставына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

2.1. Инвестиция советының төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

- Балтач муниципаль районында уңай инвестицион климат булдыру;

-Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә инвестиция климатын яхшырту, инвестиция эшчәнлеген тотрыклы гамәлгә ашыруның һәм инвестиция проектларын гамәлгә ашыруның тотрыклы шартларын тәэмин итү чараларын эшләү;

-инвестиция эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;

-Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә Балтач муниципаль районы тарафыннан җайга салынмаган инвестиция проектларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча вәкаләтле оешмалар белән инвесторларның каршылыкларын һәм бәхәсләрен судка кадәр тәртиптә хәл итү.

## II. Инвестиция советының төп бурычлары

3. Инвестиция советының төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

-Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә аларны гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы буенча инвестиция проектларын карау һәм анализлау һәм аларны җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслау мөмкинлекләре;

-дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерүнең төп юнәлешләрен билгеләү һәм Балтач муниципаль районында дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән башка бурычларны хәл итү;

-Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының социаль һәм

икътисадый үсешенә юнәлдерелгән инвестиция проектларын һәм программаларын гамәлгә ашыру өчен халыкара финанс оешмаларының финанс һәм икътисадый ресурсларын җәлеп итү максатларында халыкара финанс оешмалары белән хезмәттәшлеге мәсьәләләрен карау;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә халыкара финанс оешмалары катнашында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының тәкъдимнәрен, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районына финанс һәм техник ярдәм күрсәтү буенча халыкара финанс оешмалары тәкъдимнәрен карау;

- җир законнары нигезендә инвесторларга җир кишәрлекләре бирүгә бәйле мәсьәләләрне карау;

- инвестиция проектларын гамәлгә ашыру барышын һәм аларның нәтиҗәләрен карау;

- җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыруга вәкаләтле органның даими хисапларын карау.

## III. Инвестиция советының төп функцияләре

4. Инвестиция советының функциясенә түбәндәгеләр керә:

а) алда күрсәтелгән тәкъдимнәрне эшләү:

- инвестиция проектларын һәм программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә объектлар урнаштыру буенча;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының һәм инвестиция процессында катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча;

- административ киртәләрне киметү буенча, шулай ук рөхсәт бирү документациясен тапшыру процедурасын кыскарту һәм гадиләштерү өлешендә;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үсешенең өстенлекле юнәлешләре һәм аеруча мөһим юнәлешләрдә финанс һәм инвестиция ресурсларын координацияләү буенча;

- инвестиция процессларына муниципаль ярдәм күрсәтү һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә инвестиция активлыгын стимуллаштыру буенча;

- федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән ярдәм күрсәтелә торган инвестиция проектларының төп критерийларына бердәм таләпләр билгеләү буенча;

б) түбәндәге очракларга бәйле булган мәсьәләләрне карау:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Инвестиция декларациясе нигезләмәләрен бозу;

- инвестиция проектларын һәм программаларын гамәлгә ашыру буенча Балтач муниципаль районы һәм инвесторлар йөкләмәләрен үтәү;

в) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында инвестиция эшчәнлеген регламентлаштыра торган норматив хокукый актлар проектларын кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү.

## IV. Инвестиция советының хокуклары

5. Инвестиция советы үзенә йөкләнгән функцияләрне башкару өчен үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләргә хокуклы:

- Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасының норматив хокукый базасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;
- үз утырышларында Инвестиция советы компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне карарга һәм алар буенча карарлар кабул итәргә;
- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан үз компетенциясе кысаларында мәгълүмат соратып алырга һәм кабул итәргә;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының норматив-хокукый актларын кабул итүне таләп итә торган мәсьәләләр буенча тиешле тәкъдимнәр кертергә;
- үз утырышларына Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары һәм башка орган һәм оешма җитәкчеләрен, аларның вазыйфаи затларын чакырырга;
- Инвестиция советы утырышларында каралырга тиешле мәсьәләләрне өйрәнү һәм әзерләү өчен эш төркемнәре булдырырга.

## V. Инвестиция советы эшчәнлеген оештыру

6. Инвестиция советы турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана.

7. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район башлыгы Инвестиция советы рәисе булып тора.

Инвестиция советы рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Инвестиция советы һәм эшче төркемнәр составын, шулай ук Инвестиция советы утырышларының көн тәртибен раслый, Инвестиция советы утырышларын алып бара.

Инвестиция советы рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Инвестиция советы рәисенең беренче урынбасары башкара.

Инвестиция советы утырышларын әзерләү эшен оештыру, шулай ук Инвестиция советы утырышларында кабул ителә торган карарларның үтәлешен тикшереп тору Инвестиция советы сәркатибе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Сәркатип Инвестиция советы рәисе һәм аның урынбасарларының Инвестиция советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча йөкләмәләрен үти, Инвестиция советы һәм эшче төркемнәр составы буенча Инвестиция

советы рәисенә тәкъдимнәр кертә. Инвестиция советы сәркатибе булып Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы тора.

8. Инвестиция советы составына Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Балтач муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка дәүләт органнары, оешма вәкилләре керә, шулай ук Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары, эшкуарларның иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре, инвесторлар, белгечләр һәм экспертлар керә ала.

Инвестиция процессы субъектлары, иҗтимагый һәм башка оешмалар Инвестиция советы рәисенә Инвестиция советы составына керү өчен кандидатуралар буенча үз тәкъдимнәрен җибәрергә хокуклы.

Инвестиция советы һәм эш төркемнәре эшчәнлегендә, ихтыяҗ булган очракта, инвестиция советы составына кермәгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешма вәкилләре катнаша ала.

9. Инвестиция советы утырышлары ихтыяҗ булган саен уздырыла.

Инвестиция советы утырышлары, әгәр аларда Инвестиция советы әгъзалары составының кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы дип санала.

10. Инвестиция советы карарлары утырышта катнашучыларның ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә һәм Инвестиция советы сәркатибе имзалый торган беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Инвестиция советы рәисе тарафыннан раслана. Тавышлар тигез булган очракта, Инвестиция советы рәисенең тавышы хәлиткеч тавыш була.Инвестиция советы рәисе булмаган очракта, хәлиткеч тавышка Инвестициоя советы рәисенең беренче урынбасары ия. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, Инвестиция советы әгъзасы үзенең мотивлаштырылган фикерен язмача бәян итәргә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

Инвестиция советы карарлары шулай ук читтән торып тавыш бирү юлы белән (сораштыру юлы белән) кабул ителергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирүне уздыру тәртибе Инвестиция советы карары белән билгеләнә. Читтән торып тавыш бирү (сораштыру юлы белән) юлы белән кабул ителгән Инвестиция советы карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Инвестиция советы сәркатибе имза сала һәм Инвестиция советы рәисе раслый.

10.1. Инвестиция советы утырышының көн тәртибен һәм беркетмәсен килештерү тәртибе Инвестиция советы карары белән билгеләнә.

11. Инвестиция советы һәм эшче төркемнәр эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

2 нче кушымта
Балтач муниципаль районы
башлыгының 2023 елның
256 номерлы
«30» 10 2023
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Инвестиция советы составы**

| | |
|---|---|
| Нотфуллин Рамил Рәшит улы | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район башлыгы, Инвестиция советы рәисе; |
| Хәйретдинов Айдар Фоат улы | Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе, Инвестиция советы рәисенең беренче урынбасары; |
| Галимуллин Илшат Солтан улы | Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, Инвестиция советы рәисе урынбасары; |
| Гарифҗанов Рәдис Мәгъфур улы | Балтач район башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы, Инвестиция советы сәркатибе; |
| Инвестицион совет әгъзалары: | |
| Бахтиозин Руслан Әнвәр улы | «Сетевая компания» Приволжские электрические сети» АҖ Балтач район электр челтәрләре җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гафиуллин Раиф Нәкыйп улы | Балтач муниципаль районы Эшмәкәрләр советы рәисе, «Гранит» ҖЧҖ җитәкчесе (килешү буенча) |
| Нәбиуллин Фирдәвес Рафаил улы | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Нигъмәтҗанов Рөстәм Камил улы | «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖенең «Балтач газы» ЭПУ идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Наил Нургаяз улы | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район башлыгы урынбасары; |
| Сәгъдиев Илфат Нурулла улы | Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы; |
| Сәлахов Азат Данил улы | Саба МРУЭС КУЭС Балтач РУЭС баш инженеры (килешү буенча) |
| Таҗетдинов Равил Әсхәтдин улы | Балтач муниципаль районы иҗтимагый совет рәисе; |
| Фәтхетдинов Ильвир Мөбарәк улы | Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе; |
| Фатыйхов Ренат Сабит улы | Балтач район башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы; |
| Шәфигуллин Рафил Рәфыйк улы | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле затның җәмәгать вәкиле (килешү буенча) |